The young poet glorifies nature ("Кышкы төндә" ("At Winter Night", 1913), "Төнге буранда" ("During the Night Blizza", 1915), "Куркыныч төн" ("A Frightening Night" 1915), "Яшен астында" (" By the Light of Lightning", 1915), "Җәйге таң" ("The Summer Dawn", 1916),"Җәйге кич" ("The Summer Evening", 1916), "Көзге курайлар" ("The Autumn Kurai", 1916), "Җәйге төн" ("The Summer Night", 1916), "Күләгә " ("The Shadow", 1916)) [Isnbət, 1989, pp. 23, 35, 39, 51, 55], describes the views of his native village and makes sketches of village life ("Авылга карап" ("Having Glanced at the Village", 1913), "Авыл хәлләре" ("Village Affairs", 1913), "Күрмиләр" ("They Don't See", 1915)) [Isənbət, 1989, pp. 23, 25, 32], reflects on the fate of the Tatar woman ("Татар кызына" ("To a Tatar Girl", 1915), "Татар хатыннарына" ("To Tatar Women", 1915), "Җырла, татар кызы!" ("Sing, Tatar Girl!", 1916)) [Isənbət, 1989, pp. 35, 38, 40], shares his love experiences ("Үләр идем" ("I would Die", 1913), "Бәхет йолдызы" ("The Star of Happiness", 1914), "Таң җилендә" ("With the Dawn Wind", 1916), "Пароходта" ("On the Steamboat", 1916), "Күзләре" ("Her Eyes", 1916), "Көл әле" ("Laugh, Come On," 1916), "Ылаклы мәгаләләре" ("Ylykly Grottoes", 1916), "Фатыйма" ("Fatyma", 1916)) [Isənbət, 1989, pp. 26–27, 40–44] and his philosophical reflections ("Кызык адәм", ("An Interesting Person", 1912), "Сугыш" ("War", 1914), "Яшь күңел" ("A Young Soul", 1915), "Моңлы көй" ("A Sad Melody", 1915), "Пәйгамбәр" ("The Prophet", 1915), "Богауда" ("On a Leash", 1915), "Дүрт ягың кыйбла!" ("All Four Sides Oriented" 1916), "Тагы ..." ("More…", 1916), "Кеше тавышы" ("The Voice of Man", 1916), "Ут диңгезендә" ("In the Sea of Fire", 1916), "Sikherche" ("The Witch", 1916), "Тормыш упкынында" ("In the Whirlpools of Life", 1916) , "Сөргән" ("The Exiled", 1916), "Артык кеше" ("The Superfluous One", 1916), "Юлда" ("On the Road", 1916), "Туган ил" (" My Homeland", 1916)) [ Isənbət, 1989, pp. 20, 30–31, 33–34, 45–46, 48–49, 54–57]. At the early stage of his literary work, N. Isanbet created romantic poems. The writer sought his own way, his own unique voice. His works often appeared on the pages of mass media (the magazines "Ak yul" ("The Bright Path"), "Syuyumbike", "Ang" ("Consciousness"), "Ялт-йолт" ("The Lightnings"), and the newspaper "Сүз" ("A Word")).

During the years of his shakird's youth, N. Isanbet became the author of serious poems ("Бозылган вәгъдә" ("The Broken Word", 1913), "Качкын" ("The Fugitive", 1915), "Табигать кочагында" ("In the Lap of Nature", 1916), "Укытучы кыз" ("The Girl Teacher", 1916), "Сукбай" ("A Tramp", 1916)). According to N. Khanzafarov, these works indicated that the author remained committed to romantic themes: pure love, the beauty of nature, the search for the warmth of the soul. His creative searches were realized along expressive lines, and his creative ideals of "pure love, natural beauty, and soul" made themselves felt [Isənbət, 1989, p. 6].

N. Isanbet, together with F. Burnash, published several handwritten humorous and satirical magazines in the "Muhammadiya".

*In the poem "Кем?" ("Who?"), published in the journal* "Ak yul", *I thought of three things: God, mother, father. It means that in 1915, I still believed in God, - N. Isanbet reflects in his memoirs. - I only believed in some "philosophical" way, and such a stance was characteristic of my way of thinking until 1917. However, in 1916, it was noticeable that in poetry I behaved very independently in relation to God. For example, this could be observed in a poem, published in the journal "Ang". It contains the following lines: "Кит әле, ялган кеше, / Мин сөймимен беркемне дә, / Сөймимен җир-күк, кояшны, / Сөймимен тәңремне" ("Go away, you deceitful person, / I don't love anyone, / I don't love the whole world, / Even my Tengri), i.e. God"* [Khanzafarov, p.12].

From Kazan, N. Isanbet returned to his village as the poet who received royalties for his work. His father never ceased to be surprised at this: "*All my aspirations were to become a poet, but my father did not approve of my occupation, although he did not interfere, he never took it seriously. He was very surprised in 1916 when the fee came for a poem published in the journal "Ang": "Can money be paid for creating poems?"* [Isənbət, 2000, p. 99].

The shakirds from the city madrasahs of Kazan, Ufa, and Orenburga were distinguished by their strong craving for art. They held literary parties on their own and staged performances. In 1913, N. Isanbet, influenced by G. Kamal's work, wrote the play "Урнаш" ("The Location"). In 1914, the play "Амирхан хазрет" ("Amirkhan Khazret") followed. As early as when Naki was a shakird, he proved himself as a playwright.

During his studies at the madrasah, Burnash met the guys from the "Sayyar" company, and attended their performances together with his brother Wafa, he himself took part in their productions.

The writer's memoirs also allow us to get an idea of the periodicals, included in the reading circle of the madrasah shakirds. It is known that Sirazetdin Mullah was subscribed to a number of newspapers and magazines in the Tatar language: the magazines "Din va adab" ("Religion and Morals") Kazan, ed. Galimjan Barudi), "Ak yul" ("The Bright Path") (Troitsk, ed. Fakhreislam Ageev), "Maglumate jadid" ("The New Developments") (Ufa, ed. Lokmanhakim Khanzafarov); newspapers "Yoldiz" ("The Star") (Kazan, ed. A.-Kh. Maksudi), "Sibiriya" ("The Sibiria") (Tomsk, ed. Vagiz Navruzov), and "Tormish" ("The Life") (Ufa, ed. V. Navruzov, Z. Kadyri, G. Khabirov). Moreover, a rich library belonging to a relative from Nasibash was at shakird Naki's disposal: "Shamsenur jingi allowed me to go up to the attic of her house. That was an America not discovered by the Tatars yet! The Universe! There, in the boxes, were the revolutionary newspapers of 1905 - "Tang Yoldizi" ("The Star of the Dawn "), "Fiker" ("The Thought"), "Ural" ("The Ural"), "Azat khaliq" ("The Free People"), "Al-gasr al-jadid" ("The New Age"), "Uklar" ("The Arrows"), and "Al-Islah" ("The Reform"), you could even find the revolutionary songs of the shakird's "Сада" ("The Voice") printed on red sheets using hectograph. All of them were not state newspapers, some of them were issued bypassing censorship. This was the interesting press of its first formation years, in which the Tatars, without concern over what the authorities might think, frankly discussed social and political issues important to them, it was the press that dared to criticize the state during the tsarist power crisis, when Tatar social thought, which had been oppressed for centuries, broke free thanks to the revolution of 1905–1907.

N. Isanbet could become acquainted with this press only in the 1910s. He stated that its influence on the minds of the people did not decrease even during the years of reaction [Isənbət, Min nitschek ..., p. 14].

N. Isanbet's enlightenment activities became a logical basis and a necessary step for the evolution of his worldview - from religious to educational views, based on the best traditions of Tatar Enlightenment (Kh. Faizkhanov, S. Marjani, K. Nasyri, G. Tukai, F. Amirkhan, and G. Kamal ) The writer admitted that in his youth he was very familiar with the works of G. Kamal, F. Amirkhan, and M. Fayzi [Khanzafarov, p.12].

In his unfinished article on Jadidism, N. Isanbet states that after the revolution of 1905, the life of the Tatar madrasahs changed dramatically. Shakirds proved themselves not only in the cultural and educational spheres, but also in the arena of political struggle. Shakirds' strikes and their collective withdrawal from madrasahs became the main form of their protest. In his book, N. Isanbet recommends a number of works where these events are realistically described: G. Ibragimov's novel "Безнең көннәр" ("Our Days") [Ibragimov] and S. Ramiev's comedy "Низамлы мәдрәсе" ("The Order of Things in the Madrasah") [Rəmiev, pp. 73–92]. The shakirds spread their Sadas and Marseillaise through the press and sang them. The reprentatives of the "Islah" movement began to organize strikes in madrasahs.

For themselves shakirds wanted a worthy and interesting life where self-realization would accompany material wealth. Literary and political societies appeared in shakird subculture of the revolutionary era; there, instead of theological disputes, discussions were held on various topics, and literary and musical parties were organized.

While preparing his "Selected Works" in three volumes (1976) and his "Works" in four volumes (1989) for publication, the writer included three poems, dedicated to the life of shakirs in the Khasaniya and Muhammadiyah madrasahs. In them, N. Isanbet immortalized himself as a freedom-loving shakird. The poem "Иттифак җиңә" ("The Union Will Win") (1909) is dedicated to a clash between the shakirs and their teacher Zufar Kasimov over the living conditions [Isanbet, 1989, pp. 14–15]. Apparently, they began to fight for their rights, inspired by the example of the strikes in the madrasahs of Ufa and Kazan during the Revolution of 1905–1907. N. Isanbet's poem "Мәдрәсә истәлеге" ("The Memory of the Madrasah") tells about the conflict with the teachers of the Muhammadiya Madrasah over the release of a handwritten satirical magazine. On the cover of one of the satirical magazines it was written "әдәби, һөҗүи һәм сәяси журнал" ("literary, satirical and political magazine"). This gave rise to a rumor that the Galiya Madrasah released a political journal. In order not to deal with the police, the teachers organized surveillance of N. Isanbet, sometimes resulting in searches. Knowing about the evening search of his school desk, the young poet attached a note inside it, which read that he was not a traitor: "My soul will not tolerate dungeons, leashes and searches; / My soul is pure, it cannot work under vigilant control" [Isənbət, 1960, pp. 71, 450].

It is with great warmth that N. Isanbet remembered his studies in the madrasah. M. Usmanov recalled that during his student years, when he was visiting the aksakal, he had the opportunity to listen to his stories about the life of shakirds in the madrasah, how they had their meals, shared household chores, and were on duty. The shakird on duty swept the floors, lit the fire in the stoves, caught and took the shakirds, skipping prayers, to the khalifa. N. Isanbet told university students about the fun the shakirds had, he vividly described the "pillow battles". [Gosmanov, p. 124].

He also recalled the cases of bullying in the madrasah. In his article "Җидегенчелектә гаепленүләр" ("Accusations of Jidegianism"), N. Isanbet describes the initiatory rite "Җәдит өркетү" (Beginner's initiation): "In the old madrasahs newcomers who arrived from other madrasahs used to be tested, scared, "bashed", in order to "distort their faces", to knock them unexpectedly with a pillow, to throw felt boots at them before they managed to get back to their feet, while running around and grunting at them. The shakird could not even hide behind his curtain: we would run up to the curtain, snorting like horses and kicking. With the help of tongs we would pinch his shoulders, while gaggling like geese, trying to prevent the beginner from tearing away, we would pour handfuls of salt into his tea. The newcomer had to endure these horrors for several days, after which he was made welcome as a dear person. Later, he himself eagerly participated in such initiation rites" [Җидегенчелектә гаепленүләр, p. 3].

N. Isanbat dedicated his poem "Бер шәкерт" ("One Shakird") to the shakirds, in it he told about the bold dreams of the madrasah students:

| | |
|---|---|
| Төн... тирә якты тынычлык.<br>Ул үзен уйлый хәзер:<br>Ул – художник, ул – музыкант,<br>Ул – мөхәррир, ул – шагыйрь! | It's night ... everything is silent around him.<br>He is dreaming of himself now:<br>He is an artist, he is a musician,<br>He is an editor, he is a poet! |
| Ул – тагын, тиздән белерсез,<br>Дөньяда бер бай кеше.<br>Акча күплектән, «халыкка<br>Файда» – һәр кылган эше. | Moreover, He, you will all soon find out,<br>Will become a rich man<br>Who will generously share his wealth in deeds using it for the benefit of the people. |

| | |
|---|---|
| Ул татарга әллә ниткән<br>Зур клублар салдыра,<br>Бакчалар, фонтан, сарайлар...<br>Дөньяны таң калдыра | For the Tatars he will build<br>Unbelievably huge clubs,<br>Gardens, fountains, and palaces ...<br>He will surprise the whole world. |

[Isənbət, 1989, pp. 47–48].

In the early twentieth century, Jadid madrasahs became the cradle of national intelligentsia. N. Isanbet's unfinished book on Jadidism has very indicative statistics on graduates of the Ufa madrasah "Galiya", provided by S. Kudash, a writer: out of 1,500 students, who studied in 1906–1919, only 27 became mullahs. Among 100 acquaintances of S. Kudash, who were graduates of madrasahs, 20 became professional writers, 28 – journalists and newspaper editors, 58 -researchers, 4 - diplomats, 6 - agronomists, 3 - engineers, 3 - lawyers, 6 headed the ministries of education in the Tatar ASSR and Bashkir ASSR and Kazakhstan, two of them became artists, one – a composer, and the rest chose the teaching path [Iscənbət. Jadidchelek turinda, p. 39].

In 1965, while talking with the young writer R. Batulla, the aksakal said: "Poetry and literature were thoroughly taught in the madrasah. Modern university graduates know ancient literature worse than the shakirds of the elementary madrassas. Let alone the knowledge of the Arabic, Farsi, and Turkic languages…" [Batulla, 2007, p. 233].

"I was already a mature poet before the revolution. I'm a scientist. I'm an encyclopedist. I only started doing dramaturgy to support my family. This occupation took hold of me and I became a playwright. Am I a scientist? Undoubtedly, a scientist. However, I am a scientist without a dissertation, without a degree, without a chair! It's on the conscience of the Soviet authorities", - in this way "the people's academician" described his literary and career path in 1968 [Batulla, 1997, p. 195].

## Conclusions

N. Isanbet's works contain interesting material that sheds light on his studies at the madrasah. Based on this material, we can have an idea not only of the writer's biography, but also of the Tatars' everyday life in the early twentieth century. If N. Isanbet's romantic works recreate shakirds' everyday life with a bit of irony and satire, his memoirs and autobiographical works describe in detail shakirds' everyday and social life, their aesthetic and moral attitudes, social and individual behaviors, and relationships from the perspective of a realist writer.

**References**

Arslanov, G. (2012). *Fol'klornyi teatr Naki Isanbeta: "Idegey" i "Khodzha Nasretdin"* [Naki Isanbet's Folk Theater: "Idegei" and "Khoja Nasretdin"]. Gasyrlar avazy. No. 1/2, pp. 251–254. (In Russian)

*Ədip həm Galim* (1969) [A Writer and Scientist]. 124 p. Kazan, Tatar. kit.nəshr. (In Tatar)

Batulla, R. (2007). *Tuzga iazmagan həllər* [Unheard-of Stories]. 447 p. Kazan, Tatar. kit.nəshr. (In Tatar)

Batulla, R. (2007). *Urynnara җәннәттә Bulsyn!* [May They Abide in Paradise!]. 902 p. Kazan, Tatar. kit.nəshr. (In Tatar)

Berger, P., Lukman, T. (1995). *Sotsial'noe konstruirovanie real'nosti. Traktat po sotsiologii znaniia (Tekst)* [Social Construction of Reality. A Treatise on the Sociology of Knowledge (Text)]. P. Berger, T. Luman. 323 p. Moscow, Medium. (In Russian)

Bikbaev, R. T. (2014). *Tvorcheskii put' Shaikhzady Babicha v pamiati rodnogo naroda (k 120-letiiu so dnia iego rozhdeniia)* [The Creative Path of Shaikhzada Babich in the Memory of His Native People (on his $120^{th}$ anniversary)]. Problemy vostokovedeniia. No. 4 (66), p. 38. (In Russian)

Eko, U. (1998). *Otsutstvuyushchaia struktura: Vved. v semiologiiu* [The Missing Structure: Introduction to Semiology]. Umberto Eko; per. A. G. Pogonyaylo, V. G. Reznik. 430 p. St. Petersburg, Petropolis. (In Russian)

Eniki, Ə. (1983). *Naki Isanbet* [Naki Isanbet]. Haterdage tuenner. Pp. 3–7. Kazan, Tatar. kit. neshr. (In Tatar)

Freid, Z. (2016). *Psikhopatologiia obydennoi zhizni. Tolkovanie snovidenii. Piat' lektsii o psikhoanalize* [Psychopathology of Everyday Life. The Interpretation of Dreams. Five Lectures on Psychoanalysis]. 618 p. Moscow, Eksmo. (In Russian)

Fuks, K. F. (2013). *Kazanskie tatary v statisticheskom i etnograficheskom otnosheniiakh* [The Kazan Tatars in Terms of Statistics and Ethnography]. 108 p. Kazan', izd-vo "Poznanie" Instituta ekonomiki, upravleniia i prava. (In Russian)

Fahreddin, R. (2010). *Asar* [Monuments]. T. 3–4. 648 p. Kazan. (In Tatar)

Gabdrafikova, L. R. (2013). *Povsednevnaia zhizn' gorodskikh tatar v usloviiakh burzhuaznykh preobrazovanii vtoroi poloviny XIX – nachala XX veka* [The Urban Tatars' Everyday Life under the Conditions of Bourgeois Reforms in the Second Half of the $19^{th}$ – Early $20^{th}$ Centuries ]. 384 p. Kazan', Institut istorii AN RT. (In Russian)

Gabdrafikova, L. R. (2015). *Tatarskoie burzhuaznoie obshchestvo: stil' zhizni v epokhu peremen (vtoraia polovina XIX – nachalo XX veka)* [Tatar Bourgeois Society: Its Lifestyle in the Era of Change (the second half of the $19^{th}$ –early $20^{th}$ centuries)]. 367 p. Kazan', Tatar. kn. izd-vo. (In Russian)

Gabdrafikova, L. R. (2018). *Kul'tura chteniia v Menzelinske vo vtoroi polovine XIX – nachale XX vv.* [Reading Culture in Menzelinsk in the Second Half of the 19th – Beginning of the 20th Centuries]. Nauchnyi Tatarstan. No. 1, pp. 54–62. (In Russian)

Gabdrafikova, L. R. (2017). *Zabytaia tetrad' tatarskogo shakirda epokhi revoliutsii: 1909–1918 (vospominaniia Sharifa Zamilova)* [The Tatar Shakird's Forgotten Notebook of the Revolution Era: 1909–1918 (Memoirs of Sharif Zamilov)]. Istoricheskaia etnologiia. No. 2, pp. 346–358. (In Russian)

Gabdrafikova, L. R. (2016). *Tatarskaia literatura rubezha XIX–XX vv. kak istoricheskii istochnik* [Tatar Literature at the Turn of the 19th –20th Centuries as a Historical Source]. Tatarika, No. 7, pp.109–125. (In Russian)

Gabdrafikova, L. R. (2012). *Povsednevnaia zhizn' tatarskikh shakirdov v kontse XIX – nachale XX v.* [The Tatar Shakirds' Everyday Life in the Late 19th – Early 20th centuries]. Izvestiia Altaiskogo gosudarstvennogo universiteta. Seriia "Istoriia", "Politologiia". No. 4–1 (76), pp. 56–62. (In Russian)

Gainanov, R. (1959). *Halykka hezmatke* [Working for the Glory of the People]. Azat Khatyn. No. 12, p. 10. (In Tatar)

Galiullin, T. (2002). *Egermenche ellar tatar shigriiate* [Tatar Poetry of the Twenties]. Shig'riiat baskychlary. Pp. 72–73. Kazan, Magarif. (In Tatar)

Gosmanov, M. (2010). *Aksakallar majlesennen: Naki Isanbet tur. istelekler* [From the Assembly of the Elders: The Time of Naki Isenbet. Memories]. Kazan utlary. No. 11, pp. 121–135. (In Tatar)

Ibragimov, G. (1980). *Nashi dni* [Our Days]. 416 p. Moskva, Sovetskii pisatel'. (In Russian)

Isənbət, N. (1960). *Sailanma eserler: 3 tomda* [Selected Works in Three Volumes]. 1 t. 915 p. Kazan, Tatar. kit. neshr. (In Tatar)

Isənbət, N. (1967). *Shaihzade Babich : Istelek* [Shaikhzada Babich: Memoirs]. Kazan utlary. No. 6, pp. 127–134. (In Tatar)

Isənbət, N. (1987). *Ostazym ide* ... [He Was My Teacher]. Kazan Utlary, p. 19. (In Tatar)

Isənbət, N. (1989). *Eserler : 4 tomda* [Works in Four Volumes]. 1 t. 310 p. Kazan, Tatar. kit. neshr. (In Tatar)

Isənbet, N. (1999). *Bebi chak* (Isteleklerden) [Childhood (From Memoirs)]. Miras. No. 12, pp. 95–104. (In Tatar)

Isənbət, N. (2000). *Bebi chak* (*Isteleklerden)* [Childhood. From Memoirs]. Miras. No. 1, pp. 91–101. (In Tatar)

Isənbət, N. (No date). *Min nichek shagyir' buldym* [How I Became a Poet]. A Typewritten Manuscript from Naki Isanbet's Personal Archive. Pp.13–27. (In Tatar)

Isənbət, N. (No date). *Jadidchelek turinda* [About Jadidism]. A Typewritten Manuscript from Naki Isanbet's Personal Archive. 30 p. (In Tatar)

Isənbət, N. (No date). *Jidegenchelekte gaeplenүlyr* [On the Issue of Participation in Jideghian]. Typewritten Manuscript from Naki Isanbet's Personal Archive. 3 p. (In Tatar)

Isənbət, Yu. (2011). *Lish' trud daiet pustyniam vody* [Only Labor Brings Water to Deserts]. Kazan'. No. 2, pp. 102–109. (In Russian)

Kandalyi, G. (1988). *Shigyr'ler hem poemalar* [Poems and Verses]. 558 p. Kazan, Tatar. kit. nashr. (In Tatar)

Khabutdinov, A. Yu., Khabutdinova, M. M. (2019). *Obraz Naki Isanbeta v tatarskoi proze* [The Image of Naki Isanbet in Tatar Prose]. Filologiia i kul'tura. Philology and Culture. No. 4 (58), pp. 191–201. (In Russian)

Khanzafarov, N. (1982). *Naki Isanbet dramaturgiiase* [Naki Isanbet's Dramaturgy]. 192 p. Kazan, Tatar. kit. nashr. (In Tatar)

Khaplekhamitov, R. (2008). *Pervye gody poststalinskogo perioda v Tatarstane: vzaimootnosheniia vlasti i tvorcheskoi intelligentsia* [The Early Years of the Post-Stalin Period in Tatarstan: The Relationships between Authorities and Creative Intelligentsia]. Izvestiia Samarskogo nauchnogo tsentra Rossiiskoi akademii nauk. T. 10, No.1, pp. 136–140. (In Russian)

Kudash, S. (1959). *Həterdə kalgan minutlar* [The Minutes of Memory]. 284 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

Kudash, S. (1980). *Minem bahadir zamandashym* [My Hero is My Contemporary]. Socialistik Tatarstan. 15 gyinvar. (In Tatar)

Lotman, Yu. M. (1994). *Besedy o russkoi kul'ture : byt i traditsii russkogo dvorianstva (XVIII – nachalo XIX veka)* [Conversations about Russian Culture: Life and Traditions of the Russian Nobility (the 18th–early 19th century)]. 412 p. St. Petersburg, Iskusstvo. (In Russian)

"Ob oshibkakh v uchebnike literatury dlia 8 klassa tatarskikh srednikh shkol" (2013) ["On Errors in the Textbook of Literature for the 8th Grade of Tatar Secondary Schools"]. Istoriia tatar s drevneishikh vremen v 7 t. T. VII, pp. 861–862. Kazan', Institut istorii im. Sh. Mardzhani AN RT. (In Russian)

Ramiev, S. (1980). *Nizamly madrasə* [Order of Things in the Madrasah]. Ramiev S. Таң vakyty , pp. 73–92. Kazan, Tatar. kit.neshr. (In Tatar)

Seniutkina, O. N. *Arkhivnye materialy i istoriia povsednevnosti (o tatarskoi derevne Shubino XIX stoletiia)* [Archival Materials and the History of Everyday Life (about the Tatar Village of Shubino in the 19th Century)]. Faizkhanovskie chteniia. No. 7. URL: http://www.idmedina.ru/books/materials/?3254 (accessed: 15.10. 2019). (In Russian)

Shamukov, G. (1959). *Naki Isanbet* [Naki Isanbet]. 76 p. Kazan, Tatar. kit.neshr. (In Tatar)

Strukova, T. G. (2017). *Problema obydennosti v diskurse o literature* [The Problem of Everyday Life in the Discourse on Literature]. Vestn. VGU. Ser. Filosofiia. No.1, pp. 72–83. (In Russian)

Tukai, G. (1985). *Eserler: 5 t.* [Works: In Five Volumes]. 406 p. Kazan, Tatar. kit.neshr. (In Tatar)

Utiabai-Karimi, R. (2009). *"Khasaniia"* ["Hasania"]. Bashkirskaia entsiklopediia. T. 7. P. 128. Ufa, Bashkirskaia entsiklopediia. (In Russian)

*Vatan sezdən esh kətə!* (1980) [The Motherland Expects You to Work!]. N. Isanbetneng 1979 yelnyng 28 noiabrende "Iash' Leninchy" redaktsiiasendə suilegennerennen Shavali iazyp algannarynyng ber uleshe. Iash' Leninchy. 26 gyinvar. (In Tatar)

# НӘКЫЙ ИСӘНБӘТ ИСТӘЛЕКЛӘРЕНДӘ ХХ ГАСЫР МӘДРӘСӘ ШӘКЕРТЛӘРЕНЕҢ КӨНДӘЛЕК ТОРМЫШЫ

**Миләүшә Мөхәммәтҗан кызы Хәбетдинова**,
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
mileuscha@mail.ru.

Нәкый Сиражетдин улы Исәнбәт (1899–1992) – татар язучысы, шагыйрь, драматург, прозаик, энциклопедист галим. Туган җиренең ялкынлы патриоты булган әдип үзенең җирдәге миссиясен татар әдәбиятына, татар теленә, алар аша – татар халкына хезмәт итүдә күрә. Аның мирасында татарларның белем алу тарихы турында кызыклы мәгълүматлар бар. Татар мәдрәсәсе шәкертләре көндәлек тормышын анализларга мөмкинлек бирә торган материал язучының истәлекләреннән, шигырьләре, «Бәби чак» автобиографик повесте һәм башка архив документларыннан алынды. Бу чыганаклар безгә ХХ гасыр башында татар интеллигенциясе формалашуның объектив күренешен торгызырга мөмкинлек бирә. Н. Исәнбәтнең романтик әсәрләрендә шәкертләр һәм мәдрәсә тормышы ироник һәм сатирик планда сурәтләнсә, аның реалистик әсәрләрендә һәм истәлекләрендә мәгърифәтчел пафос өстенлек итә. Н. Исәнбәт Яңа дәвердә татар халкының уку-укыту системасы белән горурлана һәм мәдрәсәне татар милли интеллигенциясенең чишмә башы дип саный.

**Төп төшенчәләр:** татар әдәбияты, Н. Исәнбәт, татар мәдрәсәсе, шәкертләр дөньясы, көндәлек тормыш.

## Кереш

*Көндәлек тормыш* термины фәнни әйләнешкә З. Фрейд тарафыннан кертелә [Фрейд]. *Көндәлек тормыш* дигәндә, социологлар «кешеләр тарафыннан интерпретацияләнгән һәм алар өчен субъектив әһәмияткә ия булган, бербөтен дөнья буларак кабул ителгән чынбарлык»ны күз алдында тоталар [Бергер, Лукман, с. 38]. У. Эко көндәлек тормышта гаилә, төркем, халык, илнең мәдәни коды яшеренгән әһәмиятле билгеләр системасын күрә [Эко, с. 66]. Рус әдәбияты фәнендә Ю. М. Лотман, көндәлек тормыш феноменын беренчеләрдән булып өйрәнеп, аның эш көне һәм эштән тыш көнкүреш кысаларына гына сыймаганлыгын раслап чыга [Лотман, с. 13]. Татар гуманитар фәнендә көндәлек тормышны, фәнни проблема буларак, тарихчылар ([Габдрафикова, 2013], ([Габдрафикова, 2015], [Габдрафикова, 2017], [Габдрафикова, 2018], [Сенюткина] һәм этнограф Фукс [Фукс] өйрәнә.

Безнең тикшеренүебезнең методологик базасы булып Ю. М. Лотманның [Лотман] һәм Л. Р. Габдрафикованың [Габдрафикова, 2012] фәнни эшләре тора. Т. Г. Струковага иярәп, без, «әдәби әсәрдә көндәлек тормыш» дигәндә, «кешеләр көнкүреше һәм үз-үзләрен тотышының бөтен тулылыгы автор тарафыннан гамәлгә ашырылган мәдәни кодлар һәм практикаларның бербөтен системасын күз алдында тотабыз. Бу системада мәгънәләр барлыкка китерелә, объектлар тудырыла, үзгәртелә һәм индивидуумның тормышка карашы, кичерешләре белән чагыштырыла» [Струкова, б. 78].

## Чыганаклар һәм ысуллар

Безнең тикшеренүебезнең яңалыгы – татар халкының тел, әдәбият хәзинәләрен җыю, барлау, гыйльми өйрәнү һәм аларны, системага салып, бастырып чыгару өлкәсендә армый-талмый эшләгән күренекле галим Нәкый Исәнбәтнең (1899–1992) шәкертлек чорын өйрәнү. Анализлау өчен күренекле язучының

истәлекләрен ([Ватан сездән эш көтә!]), автобиографик әсәрләрен ([Исәнбәт, 1989, б. 14–15, 47–48, 71, 450], [Исәнбәт, 1999], [Исәнбәт, 2000]) һәм башка архив материалларын сайладык.

Н. Исәнбәтнең мәдрәсә турындагы хатирәләре, бер яктан, шәхси интонациягә бай булулары белән үзенчәлекле, ә икенче яктан, шәкертләрнең көндәлек тормышы хакында киң һәм бәяләп бетергесез чыганак буларак, зур кыйммәткә ия. Без, аларны өйрәнеп, XX гасыр башында татар милли интеллигенциясенең ничек формалашканлыгына төшенә алабыз. Безнең тикшеренүебезнең хронологик кысалары 1908 елдан 1916 елга кадәр чорны үз эченә ала. Татар мәдрәсәсе шәкертенең көндәлек тормышы феноменын социаль һәм фәлсәфи яктан Н. Исәнбәтнең башлангыч чор иҗаты мисалында анализлау өчен, без герменевтик (әдәби текстларны интерпретацияләү), диалектик (көндәлек тормышны бербөтен субстанция итеп күзаллау) һәм социологик методлардан файландык.

**Фикер алышу**

Нәкый Исәнбәт 1899 елның 27 декабрендә (иске стиль буенча 15 декабрьдә) Уфа губернасы Златоуст өязе Малаяз авылында мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне авыл мәктәбендә ала. 1909–1914 елларда Уфа шәһәренең «Хәсәния» мәдрәсәсендә, 1914–1916 елларда Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Галимнең ике дистә елга сузылган педагогик эшчәнлеге 1917 елда башлана. Язучы 1939 елда Әдәби фонд (Литфонд) әгъзасы була. 1941 елда гына Н. Исәнбәт К. Нәҗмидән белә 1939 елдан бирле үзенең СССР Язучылар берлеге әгъзасы булганын. 1941 елдан Н. Исәнбәт үзен тулысынча әдәби һәм фәнни эшкә багышлый. Бер яктан, фольклорчы, тел һәм әдәбият белгече, тәнкыйтьченең фәнни хезмәтләре төрки тел белемендә аның какшамас урынын тәэмин итсә (М. Госманов ([Госманов], Ә. Еники [Еники], С. Хәким [Әдип һәм галим] һ. б.), икенче яктан, татар әдәбияты тарихын классик язучының драматургиясе, шигърияте, тәрҗемәләреннән башка күз алдына китерү мөмкин түгел (Г. Арсланов [Арсланов], Т. Галиуллин [Галиуллин], Н. Ханзафаров [Ханзафаров], Г. Шамуков [Шамуков], А. Хәбетдинов, М. Хәбетдинова [Хәбетдинов, Хәбетдинова] һ. б.).

Язучының кызы – музыка белгече Йолдыз Исәнбәт – үз истәлекләрендә әтисенең тормыш позициясен болай тасвирлый: Әти «үзенең миссиясен татар әдәбиятын, татар телен өйрәнүдә һәм үстерүдә күрде; бу эш аша татар халкына хезмәт итү кебек югары бурычын үти алачагына ышанды. Ул бөек хезмәт иясе булды һәм эш, хезмәтнең теләсә нинди чагылышын хөрмәт итте. Яшьлек чорында туган бөек идеалларына гомере буе тугры калды» [Йолдыз Исәнбәт, б. 102].

Н. Исәнбәтнең истәлекләрендә һәм автобиографик прозасында XX гасыр башы татар мәгариф системасы турында зур кыйммәткә ия мәгълүматлар табарга мөмкин. Бу чыганакларда мәдрәсә шәкертләренең көндәлек тормышы кызыклы итеп тасвирлана.

Язучының әтисе Малаяз авылының мәхәллә башлыгы була: «Минем әтием дә музыкант булган, скрипкада уйнаган. Ул – Зәйнулла Рәсүли ишан шәкерте. Зәйнулла Рәсүли (1833–1917) – Троицкида ишан булган кеше. Заманында зур авторитетка ия булган шәхес, „нәкышбәндия“ дигән суфичылык тәгълиматы тарафдары. Соңыннан З. Рәсүлине патша хөкүмәте сөргенгә җибәргән, аннан ул “изге” булып кайткан. (Троицкида 1917 елның 2 февралендә вафат була.) М. Акмулла, М. Гафури, Сабир Хәсәни (Уфа мәдрәсәсе хуҗасы), Сиражетдин мулла (минем әти) һәм башка күп кенә укымышлылар – аның шәкертләре. Болар уртача, тыйнак җәдитчеләр булалар. Соңыннан Сиражетдин муллага ишан булырга да тәкъдим ителәә. Әмма, бу – зур җаваплылык дип, ул ризалашмый» [Ханзафаров, б. 12].

Сираҗетдин мулла Р. Фәхретдин белән дә таныш булган, язучы җитәкләгән фәнни проектта да катнашкан. «Асар» китабында ул язган «Гыймадеддин бине Сәйфулла бине Мөхәммәдрәхим» исемле мәкалә бар [Фәхретдин, б. 419]. Үзенең мәхәлләсен төзекләндерү өчен, имам-хатыйб бик күп эшләгән, кибет, мәдрәсә, мөгаллимнәр тоткан. Сираҗетдин мулла аркасында авыл хастаханәле булган. Л. Р. Габдрафикова фикеренчә, татар ир балалары, нинди иҗтимагый катламнан булуларына карамастан, мәҗбүри башлангыч белем алганнар. Мөселман руханиларының балалары һәм хәлле гаилә әгъзалары, муллалыкка имтихан тотар өчен, мәдрәсәләрдә укуларын дәвам иткәннәр. Татар җәмгыятендә дини гыйлем югары бәяләнгән, мулланың матди хәлен мәхәллә кайгырткан. Һәр татар

гаиләсе өчен улларын мулла итеп тәрбияләү зур казаныш булган, шуның өчен ата-аналар моңа акча кызганмаган. Нәтиҗәдә, мөселман руханилары йомык катлам булып яшәмәгән, аларның сафлары сәүдәгәр, крестьян һәм мещан балалары белән дә тулыландырылган [Габдрафикова, 2013].

Н. Исәнбәт архивында җәдидчелек хәрәкәтенә багышланган кульязма саклана. Ул кульязмада татар даирәсендә «шәкерт» сүзенең кулланылышы турында кызыклы мәгълүмат бирелгән [Җәдидчелек мәсьәләсе, б. 152–153]. Бу мәкаләне галим җәдидчелек тирәсендә барган кискен бәхәсләр чорында – 1950–1960 елларда язган дип фаразлыйбыз. Билгеле булганча, 1953 елда Н. Исәнбәтне ВКП (б) обкомы бюросының 1952 елның 18 гыйнварындагы «Татар урта мәктәпләренең 8 сыйныф әдәбияты дәреслегендә хаталар» карарын үтәмәүдә гаеплиләр. Бу карарда җәдидчелек – «пантюркизм һәм панисламизм идеологиясен» алга сөргән «буржуаз-милли хәрәкәте» дип билгеләнә. «Октябрь инкыйлабыннан соң җәдидчеләр милли контрреволюция тарафдарлары рәтенә керә» [ВКП (б) Татар обкомы бюросының «Татар урта мәктәпләренең 8 сыйныф әдәбияты дәреслегендә хаталар» дигән карары, 861–862 б.] Н. Исәнбәт исә «җәдидчелекне яклауда, аны мәгърифәтчелек белән тиңләштерүдә» гаепләнә. ТАССР язучыларының II һәм СССР язучыларының III Съезды алдыннан аның «Миркәй һәм Айсылу» пьесасы тар-мар ителә, драматургның дөньяга карашында өстенлек иткән «милли» тенденцияләр кискен тәнкыйтьләнә. [Хаплехамитов, б. 138].

Нәкый Исәнбәт үзенең «Җәдидчелек мәсьәләсе» исемле хезмәтендә болгар чорыннан ук татар халкында шәкертләрнең хөрмәткә лаек кешеләр булуы турында яза: *«„Шәкерт“ сүзе безнең үз халкыбызда гомумән хөрмәт белән әйтелгән кебек, шәкерт үзе дә хөрмәтле кеше саналган».* Татар халык мәкальләрендә дә укуга, белемгә, шәкертләргә зур хөрмәт белән карау сизелеп тора: *«Юлдан килгән мөсафир шәкертне кунак итү бик саваплы эш саналып, шәкерт «алла кунагы» дип йөртелгән. Ләкин XX гасырда реформалар нәтиҗәсендә җәмгыятьтә шәкертләргә булган уңай караш үзгәрә. Татар мәдәниятеннән ерак кешеләр шәкертләргә кимсетеп карыйлар, аларны «белемсез», «Европа тәрбиясе алмаган» кешеләр итеп санайлар».* Бу стереотип, Н. Исәнбәт фикеренчә, рус уку йортларында белем алган, нәтиҗәдә, милли мәдәнияттән ераклашкан морза балалары даирәсендә формалаша. Алар мәдрәсәдә укучыларның тышкы кыяфәтен, киемнәрен, үз-үзләрен тотышларын алдан ук тискәре итеп бәялиләр. XX шасыр башында җәдиди мәдрәсә шәкертләренә кадими мәдрәсә шәкертләренә караганда зуррак хөрмәт белән карыйлар. Шәкертләр исә бер-берсеннән белем дәрәҗәләре белән генә түгел, тышкы кыяфәтләре белән дә аерылып торалар: *“Кадим шәкерт, башын кырган, камзул, җилән, ыштаннан. Очлы, саргылт фәс киеп йөрсә, җәдит шәкерт кәләпүш, астына яшереп булса да, чәч җибәргән, өстә пиджак, чалбар, пальто, фуражка, яки кырлы кызыл фәс кия. Җәен эшләпәдән, аякта штиблет, кулда таяк та йөртә. Бу кыяфәт, аның европача мәгълүмат мәдәният дәгъвә кылган кеше икенен тышыннан ук күрсәтергә тиеш. Димәк, бар шәкерт, бар шәкерт...».* Кадими мәдрәсәдә схоластика рухы хакимлек итсә, җәдиди мәдрәсәләр дөньяви белем бирүгә юнәлеш тота. Иң яхшы мәдрәсәләр рәтенә Н. Исәнбәт «Иж-Буби», «Галия» (Уфа), «Хөсәения» (Оренбург), «Мөхәммәдия» (Казан), «Вазифа» (Троицк) мәдрәсәләрен кертә. Җәдиди мәдрәсә шәкертләре кадими мәдрәсә шәкертләренә өстән генә карыйлар [Җәдидчелек мәсьәләсе, б. 152-153]. Шул рәвешле, XX гасыр башында шәкертләргә, нинди мәдрәсәдән булуларына карап, төрле караш тәрбияләнә.

Башлангыч белемне Нәкый Исәнбәт әнисеннән – Таибә абыстайдан ала. Ул өендә, кызларны укыту өчен, «сабак йорты» тота торган була: *«Минем анам, татар хатыны, минем җисememне дөньяга китереп кенә калмаган, мин тугач та, иң элек минем рухи байлыгымны кайгырткан, телем кешегә татлы, ягымлы булсын дип, мине бал-май белән авызландырган. Бу әз нәрсәмени? Аракы белән түгел ләбаса! Туганда сөйләр телем юк, ул миңа үз телен биргән. Рәхмәт аңа, ул миңа тел аңы – уй-мәгънә бирүе белән мине аталы-аналы, туган халыклы һәм шуның белән тарихлы, үз мәдәниятле иткән, бәхетле иткән»* [Исәнбәт. Мин ничек..., б. 13].

Н. Исәнбәт «Бәби чак» исемле автобиографик повестенда Малаязда кызларны укытуның ничек куелуын тәфсилләп тасвирлый. «Сабак йортында» тәрбияләнүчеләргә, көйләп укырга өйрәнү өчен, бер ел кирәк булган. Остазбикәдә дәресләр иркле булган, чөнки алар конкрет вакытка бәйләнмәгән:

*«Кечкенәдән башлап буй җитеп килгән кызлар, әнкәй алдына килеп сабак алгач, сәке казнасы буенына аяк салдырып, сабакларын кат-кат кабатлап укыйлар. Кызларның берсе килә, берсе кайтып китә, сәгать юк, һәркемгә үзенә иде. Һәркайсының укуы китапның төрле җиреннән иде.*

*Һәр кыз сабагын көйләп укый, хәтта хәреф көйләп әйтелә иде. Шулай бер ел көйләп йөргәч, әллә ничек кенә укырга да өйрәнеп чыгалар иде. Вак кызлар олы кызлар алдына идәндә тезләнеп, чүгәләп йөреп, йә алар артына сәкегә тезләнеп утырып көйлиләр. Шул ук вакыт алларында утырган зур кызларның чәч толымнарын да рәтләштереп алалар иде. Буйчанрак кызлар китапларны кычкырып, көйләп укыйлар. Аларның китаплары төрле булган кебек, бите дә аерым-аерым үзенә бер җирдән иде»* [Исәнбәт. Бәби чак, 2000, б. 92]. Уку китаплары арасында «Бакырган китабы», Бакырганиның «Хәзрәте Мәрьям ана разыйаллаһы ганһә» поэмасы, дини-мифологик хикәяләр җыетыгы «Ярым алма китабы», Кол Галинең «Йосыф китабы» була.

Кечкенә чакта Нәкый сабак алган кызларга, кәгазьдән очлы бүрек ясап, төрле фокуслар күрсәтә: *«Мине үз өебездә, үз сәкебездә, авыл кызчыклары белән бергә көйләтеп, "Бәдәвәм"нар әйттерде, ягъни хәреф тану белән, минем кулыма "Йосыф китабы"н тоттырып, борынгы Болгар, Казан ханлыгы чоры әдәбиятын төшендерде. Күрәсең, без үзебез патша вакытында чабатага калган булсак та, бабаларыбыз итек кигән, асылда без чынлап та борынгы зур культуралы халык балалары икәнбез, чөнки үз сәкебездә, без шул чабаталы авыл кызыйлары белән бергә үзебезнең шул меңьеллык классик әдәбиятыбызны кулларыбызга тотып, нәкъ борынгы үз язма төрки телендә үк көйләп укырлык хәлдә булганбыз...* [Исәнбәт. Мин ничек..., 2000, б. 13]. Нәкый мәдрәсәдә укыганда, бу китапларның 8–9 гасыр элек язылганын белгәч, нык гаҗәпләнә. Борынгы әсәрләрнең теле Малаяз хәерчеләренең көйләп әйткән мөнәҗәтләр теленнән аермасыз булуы Сираҗетдин мулла малаен сокландыра да, уйланырга да мәҗбүр итә. Шул чорда Нәкый Исәнбәт әдәби телнең борынгы булуына инана.

*«Рәхмәт әнкәемә: ул мине уку-язудан кызык һәм мәгънә табарга, үз әдәбиятыбыздан ямьтәм һәм рухи азык алырга өйрәтте, киләчәктә үзем дә язучы булуыма нигез салды, юл ачты.–* дип, хатирәләрендә әнисенә рәхмәтен белдерә язучы [Исәнбәт. Мин ничек..., 2000, б. 13].

1908 елдан Нәкый Исәнбәт Малаяз авылы башлангыч мәктәп-мәдрәсәсенең өченче сыйныфына йөри башлый: *«Бу – ярым җәдитчә мәдрәсә. Монда татар әлифбасы белән укытыла, гарәпчә түгел. Казанда басылган әлифба китаплары килә. Бала ана телендә уку таныгач кына, төрки өйрәнә, әдәбият (Г. Тукай, М. Гафури һәм башкаларның әсәрләре), хисап, география, кыйраәте төрки (төрки телендә уку) өйрәнә. Тарих фәне үтелә ("Тарихел әнбия", ягъни "Пәйгамбәрләр тарихы"), татар тарихы юк иде. Югарырак классларда гарәпчә укырга өйрәтәләр (Коръән, догалар һ.б.)»* (Цит.: [Ханзафаров, б. 11–12]). Кечкенә Нәкый биредә татарларның бүгенге дөньясы һәм хәзерге тормышы турында белемен туплый башлый: *«Монда хәзрәти Мәрьям, Бакырганнан түгел, кулында Тукай, Гафури шигырь китаплары»* [Исәнбәт. Мин ничек..., 2000, б. 13].

Дәресләр тәртибе бик үзенчәлекле була: *«Мәктәптә иң беренче дәрес – шигырь әйтү була иде. Мәктәптә көн Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури шигырьләреннән көйләп әйтү белән башланып китә иде. Көйләп шигырь әйтү ул – ритмга, тәртипкә өйрәтү, дисциплинага тарта, укучыларны тынычландыра, аларга көне буена җитәрлек кәеф бирә. Инде шуннан соң бүтән дәресләрдә дә беркем дә кычкырып та, шаулап та утырмый»* [Ватан сездән эш көтә!].

Бу чорда «яңача укытыла торган авыл мәктәпләрендә дәрес алдыннан һәм азагыннан хор белән Тукай, Гафури һәм Бәшири шигырьләрен җырлау гадәткә кереп киткән иде. Укытучылар моны "Мөнәҗәт әйттерү" сылтавы белән эшләделәр һәм программага җыр дәресләре керттеләр. Халыкның үзе тарафыннан иҗат ителгән көйләргә җырлана торган бу җырлар Тукай һәм Гафури шигырьләренең халыклашып китүләренә вакытында бик зур хезмәт иттеләр» [Кудаш, б. 23].

Шәкертләр өйләрендә дә туганнарына шигырьләр көйләп укый торган булалар: *«Хәтеремдә: безнең өйдә хатын-кызлар мәҗлесе бара иде. Габдрахман абый: "Алар җыен юк-бар сүз сөйләшеп утыралар, бар әле, «Шүрәле»не кереп укы әле шуларга!" – ди. Ә минем өчен шигырь укудан да рәхәт эш юк. Кердем дә, укый да башладым. Апалар, җиңгиләр тәмам аптырап утыралар, китап*

*тыңлагандай тыңлыйлар. Мин аның саен дәртләнебрәк укыйм. Җиңгиләр чынаякларын да оныттылар хәтта. Онытылмаслыкмыни: үзебезнең телдә бит! Мин укып бетергәч, беравык таң калып тын гына утырдылар. Шуннан берсе торды да: – Мә, шәкерт, дога кылып ал! – дип, миңа унбиш тиенлек көмеш бирде. Беләсегез килсә, әнә шул булды минем беренче гонорарым!»* [Ватан сездән эш көтә!].

Хатирәләрендә Н. Исәнбәт Шәмсенур җингисен рәхмәт сүзләре белән искә ала: *«Гаҗәп ягымлы, малахит күзле Шәмсенур җиңги, Шакир абзый хатыны, миңа бик ошап китте». «Мин язган шигырьләремне тәвәккәлләп аңа күрсәтә башладым. Шигырьләр күп инде. Билгеле, алар балача».*

*«Ул Малаязга килен булып төшәр елны бер шулай үз өйләрендә мине үзенең энесе Мөнир белән янәшә үз каршына утыртты да кулына Габдулла Тукай шигырьләре китабын алып ачты. Аннан бер шигырь сайлап, – тыңлагыз! диде, шигырьнең юлларын үзе көйләп укып чыкты, китапны алдыбызга салды, шуны көйләп әйтергә кушты. Бу "Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә" дип аталган шигырь иде. Тукайның саф татарча шигырьләрен без, малайлар, үлеп яратабыз, ләкин бу шигыре гарәпчә катыш, авыр... Шәмсенур тәтәй нигә аны бездәй көйләтеп әйттерә? Соңыннан гына аңладым. Хикмәте шул, бу шигырь беренче татар әдибебез булган Заһир Бигиевкә багышлап язылган бит. Шәмсенур тәтәй, әлбәттә, бу язучының "Гүзәл кыз Хәдичә", "Гөнаһы кәбаир" дигән романнарын укыган, Тукай исә шул яңача беренче роман язучы әдибебезнең кабер башында торып, аның үлемсезлеген җырлый. Акыллы Шәмсенур җиңги, күрәсең, безгә бу шигырь аша әдәбият һәм әдипкә хөрмәт уятмакчы була. Һәрбер кош, үз телендә сайрап, җыр тудырып куанган кебек, язучы да үз телендә дөньяга үз күңеленнән әсәр тудыра, ачыш ясый икәнен, бу иҗатның шул телдә сөйләүче үз туган халкың өчен нинди бөек табыш икәнен, шундый өстен идеал өчен көрәшнең мәгънәсе нинди зур икәнен кызыктырып сөйли, безнең яшь күңелебезгә шигырь дәртен салмакчы була иде. Һәм без бу шигырьне кат-кат әйтә торгач, мәгънәсенә дә төшенеп җиткәч, аны мандолинага кушылып көйләп әйтә торган булып киттек»* [Исәнбәт. Мин ничек..., б. 14].

Сираҗетдин мулла кибетендә еш кына шагыйрьләр турында фикер алышулар була. Г. Тукай, М. Гафури шигырьләрен уку белән беррәттән, һәвәскәр шагыйрьләр үзләренең иҗат җимешләрен дә тәкъдим итәләр. Истәлекләрдә сүз япон сугышы ветераны Габдрахман Ганиев, Мәгъсүм абзыйлар шигырьләре турында бара: *«Кулындагы аршынга таянган әткәй аларның шигырьләрен тагын нindидер бер күзгә күренмәгән, «гаруз» дигән серле бизмәнгә салып, кулындагы аршынын да уңга-сулга яткырып, шуны үлчәгән кебек итеп күрсәтә. Бу җире гарузга килгән, бу җире килмәгән, ди. Фагыйләтен фагыйләт, ди[2].. Ул үзе дә – шагыйрь»* [Исәнбәт. Мин ничек..., б. 14]. Еш кына сатып алучылар, кибеткә шикәр-тоз алырга килүләрен онытып, бу шигъри диспутларның тамашачыларына әверелгәннәр.

«Татар шигърияте җиле» XX гасыр башында өлкәннәрнең генә түгел, балаларның да акылларына хуҗа булып китә. Н. Исәнбәт үзенең истәлекләрендә шәкерт сандыкларында булган хәзинәләр турында сүз алып бара: *«Без укып йөргән чакларда һәркемнең бәләкәй генә матур бер сандыгы, һәм ул сандыктагы китап-дәфтәрләр янында бер шигырь альбомы була иде...». «Безнең да бәләкәй чакта шундый гүзәл гадәт бар иде. Ул чактагы дәфтәрләремне мин әле дә истәлек итеп саклыйм»* [Ватан сездән эш көтә!].

Беренче шигырьләрен Н. Исәнбәт 10 яшендә яза башлый [Исәнбәт. Мин ничек... , б. 14]. Шуның аркасында Малаяз мәдрәсесендә укыган чорда үзеннән өлкәнрәк шәкертләр белән дуслашып китә (Фәтхулла абзый, Михран абзый). Дуслары очрашу вакытында, озак итеп үгетләгәч, сандык төбендә яшереп куйган шигырьләрен укый торган булалар. Элегрәк балалар арасында шигырьләр турында фикер алышу гадәте булмаган, алар үз иҗат җимешләрен олыларга күрсәтергә дә оялган. Ярлы гаиләләрдә үскән бу балаларның иҗади потенциалы шунлыктан үсмичә юкка чыккан [Исәнбәт. Мин ничек..., б. 14].

1910 ел башында Нәкыйны Уфадагы «Хәсәния» мәдрәсәсенә урнаштыралар. Аны

[2] Төрки шигъриятә Ә. Ясәви, Бакыргани чорларыннан ук беренче сүзне кабатлау рифма төзүдә еш кулланылган алым булган. *«Фагыйләтен, фагыйләтен, фагыйләт, / Сәңа, Фәрхи, күп сәламлят кямилят»* дип язып калдырган Г. Кандалый «Фәхри» исемле поэмасында [Кандалый, б. 355]. Г. Тукай бу алымны «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасында файдалана: «Фагыйләтен, фагыйләтен, фагыйләт, / Ну, Печән базары халкы күңле шат!» [Тукай, б. 276].

(рөшдияне) 1914 елда бетереп, ул урта белем алу турында аттестат ала. Бу уку йорты 3 нче җәмигъ мәчете каршында эшли. 1903 елда мәдрәсәгә мөдир М. С. Хәсәнов хөрмәтенә исем кушыла. Сираҗетдин мулла бу шәхес белән Троицк мәдрәсәсендә уку чорыннан ук дус була. Мәдрәсә Олы Кузнецкий урамының 15 номерлы йортында ике катлы кирпеч бинада урнашкан була (бүгенге көндә Б. Нуриманов урамы) [Утябай-Карими, б. 128]. Г. Шамуков фикеренчә, *«ул шактый алдынгы уку йорты була. Анда дини дәресләр белән беррәттән арифметика, геометрия, җәгъләфия, тарих шикелле дөньяви фәннәр дә укытыла. Шулай да аның программасы, Уфа шәһәрендәге «Галия» мәдрәсәсе белән чагыштырганда, шактый чикле була»* [Шамуков, б. 4]. Сабир хәзрәт мәдрәсәсе программасында гарәп теле, уку һәм риторика, сарф (морфология) һәм нәхү (синтаксис), Коръән, тәҗвид һәм тәфсир, гыйльме халь, гакаид, әхлак, хәдисләр, фикх, татар теле, арифметика, тарих, җәгъләфия фәннәре була. Шәкертләр, уку өчен, елга 2–15 сум түли. Ярлы гаиләдән булган балалар түләүдән азат ителә (алар 15% тәшкил итә). 70 шәкерт мәдрәсәнең түләүле пансионында яши. 1910–1911 елларда мәдрәсә хисабына 1200 сум акча тотыла. Бу чыгымнар хәйрия (200 сум), Уфа шәһәренең ярлы мөселманнар попечительствосының еллык пособиеләре (200–300 сум), шәхси иганәләр белән каплана [Утябай-Карими, б. 128].

1967 елда язган хатирәләрендә Н. Исәнбәт үзе укыган мәдрәсә тормышын язып китә: *«Ул чагында Өфедә Кузнецк дигән урамда, бер катлы агач өйләр арасында, «Хәсәния» дигән таш мәдрәсә бар иде. Күз алдыгызга китерегез: тар гына агач баскычтан йортның икенче катына менелә. Ишекне ачып керүгә бер якта мич, каршы стена буенда өсте-өстенә өеп куелган кыска аяклы, озын буйлы парталар. Шунда камзул-түбәтәйле малай шәкертләр. Аннан үтеп каршы ишектән шундый ук икенче бүлмәгә, ансыннан да үтеп өченчесенә керәсең. Бу түр бүлмә дәресханә дип атала. Анда пишкадәмрәк шәкертләр торалар.*

*Монысына килеп керүгә бераз караңгы. Бары тик түгәрәк, биек калай мич белән шкаф арасыннан төшкән яктылык сызыгы гына сине бүлмә уртасына китереп кертә. Бер көнне шул яктылык сызыгы буйлап бүлмәгә буй җиткән ике егет килеп керә. Алар уртадагы әлеге калай мич янына басып, бүлмәгә бер күз салып алгач, һич тә исләре китмәгән кыяфәттә генә шул мич янына ук как идәнгә утыралар. (Мәдрәсәдә утыргыч юк.).*

*Ис китәргә монда бит алар өчен әллә ни ят нәрсә юк, бар да ул заман өчен табигый күренеш – күз алларында биек кенә бер бүлмә. Идәндә стена буйлап җәелгән киез-келәмнәр, алар өстендә кыска аяклы тәбәнәк өстәлләр. Ул өстәлләрнең түр башларында өелгән китаплар. Бүлмәнең иң түр почмагы, билгеле инде, казый һәм пишкадәмнәр урыны. Ләкин бүген анда беркем дә юк. Башка өстәлләр тирәсендә да бер-ике шәкерт кенә күренә. Бүген ял көне – җомга көн итеп, күрәсең, аларның күбесе калага-нигә чыгып киткәннәр»* [Исәнбәт, 1967, б. 127].

Текстолог Р. Гайнанов хатирәләрендә Нәкый-шәкертнең бик тәфсирле портреты сакланып калган: *«Такта сандык аскан, кызыл киндер ыштанлы, яланаяк үсмер бервакыт Уфа урамнарында күренә. Көне буе каланы карап йөри, эченә керергә базмыйча, читтән-читтән генә, матур бакчаларга, андагы фырт егетләргә, кокетка кызларга гаҗәпләнеп карый, афишаларны укып чыга. Ниһаять, Нәкый «Хәсәния» мәдрәсәсендә. Такта сандыгын ачып, берәм-берәм «әсәрләрен» чыгарып, шәкертләргә укый».* [Гайнанов, б. 10]

Яшь Нәкый үзенең шигырьләр язуы белән шәкертләр арасында тиз танылa. Язучының хәтирәләрендә без аның автопортретына тап булдык: *«почмакта, тәбәнәк өстәл янында аяк бөкләп ябык кына бер малай шәкерт утыра. Түбәтәйчән, камзулчан... Кулында каләм. Өстәл астыннан дәфтәрен чыгарып алдына сала да, бик тәмләп, шул дәфтәр битләренә текәлә. Минем өчен җомга көннең бар рәхәте – шушылай кешесез генә калып, аулакта утыру. Менә бүген дә мин, яңагыма таянып, алдымдагы шигырьләремне эчемнән генә укыйм. Яратам шуларны... Дөньяда шуларны яңадан бер кат күздән-күңелдән кичерүдән, кайбер юлларын тагын да матуррак итеп төзәтүдән да ләззәтле эш юк. Чөнки болар бит минем үз шигырьләрем»* [Исәнбәт, 1967, б. 127–128].

Шигырь чыгаручы малай турында хәбәр «Галия» мәдрәсәсенә дә килеп җитә. 1913 елның март башларында Нәкыйнең калын шигырь дәфтәрләре Сабир мәдрәсәсенә казах дусты Әхмәд Маминов белән кунакка килгән Шәйхзадә Бабич кулына керә. Шигырь дәфтәрләрләренең тышлыгына «Башкортлар өчен чиккән аһ-вә хәсрәтләрем», «Күңел кояшы», «Яшьлек дәверемдә»... исемнәре

язылган була. Н. Исәнбәт «Галия»некеләргә үзенең кулъязма журналларын да күрсәткән. Дәфтәрләр иясенә бер ай артык узгач кына кире әйләнеп кайталар. Ул вакытта Ш. Бабич Уфада шактый билгеле шәхес була. Ул кулъязма рәвешендәге «Кармак», «Парлак» журналларын чыгаруда, «Милли көйләр, сәхнә һәм әдәбият түгәрәге» концертларын оештыруда катнаша. [Бикбаев, б. 38]. Мәгълүм булганча, Ш. Бабич 46 багышлау яза. Шәкертлек елларында ук «әдәби көчләр сафына баскан» Ш. Бабич Н. Исәнбәтнең беренче шигырьләрендә үк олы талант чаткысын күреп ала («Яшә, Нәкый!») [Шамуков, б. 5]. «Галия» мәдрәсәсе шәкерте Н. Исәнбәттә фикердәш, көрәштәш, милләтенең тугры улын күрә.

Н. Исәнбәт «Хәсәния» мәдрәсәсендә укыган чорда М. Х. Хәсәнов, Ф. Гайнетдинов, Ф. Такаев, Ә. Хабибуллин, Х. Яфаев, Х. Халиков, Н. Биккениннар укытканнар.

Бу елларда Уфадагы Болохин китап кибете китапларны укучыларга файдалануга биреп тору тәртибен кулланган. *«Магазин хуҗалары, китапның зурлыгына карап, укып чыгарга биреп торган өчен, китап башына бер тиеннән алып ун тиенгә чаклы акча түләтәләр»*, – дип яза С. Кудаш үзенең хәтирәләрендә [Кудаш, б. 16].

Җәйге каникул вакытында авылга кайткач, кечкенә Нәкый сатирик кулъязма журнал чыгара башлый. Бер елны ул журнал «Балта» исеме белән чыкса, икенче елны «Балга» («Кувалда») булып дөнья күрә, өченче елны «Күсәк» дип атала. Ул артталыкны, наданлыкны, икейөзлелекне, искелекне һәм башка төрле тискәре якларны камчылый. Гади дәфтәр зурлыгында чыгарылган бу журналларда Малаяз авылындагы сабыйларча бер катлы мәзәкләр, көлкеле очраклар белән беррәттән, Златоуст шәһәрендәге хәлләр, Балкан сугышы вакыйгаларына караган материаллар да урын ала [Шамуков, б. 6]. *«Мин үзебезнең Малаяз авылы өчен үземчә әдәби-сатирик журналлар чыгара идем. Һәммәсенә дә: “Нәшире – Нәкый Закиров” дип куйганмын. Исәнбәт фамилиясен мин соңрак алдым – ул минем җиденче бабам. Менә ул журналларның берсендә “Ике балтачы турында хикәя” бар. Ә менә бусындагы язмама хәтта «роман» дип үк куйганмын. Ә миңа ун-унбер яшьләр. “Күсәк” дигән журнал чыгара идем»*, – дип яза Н. Исәнбәт үзенең хатирәләрендә [Исәнбәт. Мин ничек..., б. 13].

*«Шәмсенур җиңги аларны үзе генә укып калмый, кичкә таба үзләренең кибет алдына чыгып, шунда кичке ялга җыелган авыл агайларына да кычкырып укый иде. Чөнки журналда авылыбыз чагыла бит:*

Безнең урам такырдыр,
Такыр түгел бакырдыр;
Динкәй агай – туксан тугыз
Ат алышкан батырдыр.

Малаязның уртасында
Ногыт сала Гыйльметдин,
Ногыт салса да Гыйльметдин,
Бер нәрсә дә белметдин...», –

дип, еллар узгач, истәлекләре белән уртаклаша Н. Исәнбәт [Исәнбәт. Мин ничек..., б. 13–14].

Язучының сатирик таланты бик иртә формалашканын бу шигырьдән ачык күрәбез.

*«Без Тукай шигырьләрен укып үстек. Ул язган шигырьләрне ышанып укый идек. Аның “Балалар күңеле” дигән китабындагы шигырьләрне яттан укып, көйләп үстек без. Бу хәл минем башлангыч иҗатымда чагыла».* Г. Тукай үлгәч, аңа багышлап Нәкый махсус сан чыгара [Ханзафаров, б. 12].

Н. Исәнбәт шигъри Парнаска Гомер, Байрон һәм Тукай дәрәҗәсендә менү турында хыяллана: «*Зур шагыйрьләрдән Тукаев булса хәлфә, мин – шәкерт!»* [Исәнбәт, 1989, б. 27]. «Тукай үлде», «Мәрхүм Тукаевка», «Тукай – остаз» дигән шигырьләрендә укучылар белән үз кайгысы белән уртаклаша [Исәнбәт, 1989, б. 25, 27]. Н. Исәнбәт өчен Г. Тукай – йолдыз: *«Нур иде, йолдыз иде, аһ!».* Мәдрәсә шәкерте шагыйрьне туган телнең бөтен байлыгын күрсәтә алуы өчен данлый: *«Ул, матурлап, безгә күрсәтте туган илнең телен»* [Исәнбәт, 1989, б. 25].

Ф. Урманче үзенең тикшеренүләрендә Н. Исәнбәтнең балалар фольклорының беренче үрнәкләрен 1911–1913 елларда, әле мәдрәсәдә укыган чагында, каникул вакытында җыйганын билгеләп үтә [Әдип һәм галим, б. 43]. *«Менә табышмаклар дәфтәре. Бер ягына сорауларын, икенче ягына җавапларын язганмын. Ә җавапны уку өчен, дәфтәрнең астын өскә әйләндереп карарга кирәк»* [Ватан сездән эш көтә!], – дип яза ул үзенең хатирәләрендә.

Кечкенә Нәкый чәй савытларына төшерелгән рәсемнәрне җыя торган булган. Аның коллекциясендә Һиндстан, Мисыр, Төркестан һ. б. архитектура күренешләре булган меңнән артык рәсам булган. Шулай итеп

Нәкый рәсем сәнгате һәм архитектура белән кызыксына башлый.

«Бәби чак» исемле автобиографик повестенда Н. Исәнбәт Зәки абыйсы белән «Хәсәния» мәдрәсәсендә укыган чорын тасвирлый. Мәдрәсәгә кергәнче, язучының олы абыйсы ике ел рус сыйныфында укыган. Шуңа күрә ул, Уфага килгәч, шәһәр егетләре белән бик тиз якыная. Зәки, табигате белән техникага сәләтле булганлыктан, киләчәктә мулла булырга ниятләми. Ул «барахолка»дан, сыйныфташларыннан төрле «тимерләр» (ватык револьверлар, фотоаппаратлар һ. б.) сатып ала, үткәргечләр белән мәш килә. Томас Эдисон китабы аның өчен өстәл китабына әверелә. Нәкыйның абыйсы, тәҗрибәләр үткәрү өчен, хәтта кечкенә электр лампалары да ясый. Әтиләре биргән акчалар Зәки кулында булганлыктан, ул аларны үзенен хоббиена сарыф итә. Шунлыктан алар абыйлы-энеле ачлы-туклы яшәргә мәҗбүр була. Уфа мәдрәсәсендә укыганда, Нәкый шактый ябыга, кайвакытта баш әйләнүдән интегә. Ләкин бу көнкүреш кыенлыклары аның рухын сындырмый. Хатирәләрендә Зәки абыйсы турында ул сокланып яза [Исәнбәт, 2000, б. 100]. Үзенең буш вакытын Нәкый укуга һәм иҗатка багышлый. Мәдрәсә укытучылары шәкерткә хөрмәт белән карыйлар.

Н. Исәнбәтнең язучы биографиясе рәсми рәвештә 1914 елда башланганы билгеле. «Ак юл» журналының баш мөхәррире Фәхрислам Агиев яшь шагыйрьне редакциядә колач җәеп каршы ала һәм, яшь булуына карамастан, «Хәсәния» мәдрәсәсе шәкертенең балалар өчен шигырьләр язуын үтенә: «*Ул елларда мәктәпләр күпләгән шигырь сорыйлар иде. “Ак юл” дигән балалар журналында беренче шигырем басылып чыккач, Троицкидан миңа – авылга – дәрестә укыр өчен шигырьләр җибәрүемне сорап, хат язганнары хәтеремдә. Ә мин үзем ише малайлар белән яр башында ат булып уйнап йөрим...*» [Ватан сездән эш көтә!]. Шунлыктан башлангыч чор әсәрләренең бер өлеше балалар өчен язылган. Алар арасында «Шүрәле» (1910), «Келдер-келдер...» (1911), «Сыерчык» (1912), «Алмагач һәм сандугач» (1913), «Ярканат» (1915) «Сусылу» (1916) «Аждаха» (1916) шигырьләре [Исәнбәт, 1989, Б. 15, 17, 19, 50, 53], «Елан патшасы» әкияте [Исәнбәт, 1974, Б. 116–137] бар.

*«Һәр кайда мөгаллимәләр хәрәкәте башланган, алар җитешми, аларга җыр кирәк, һөнәр-сәңгәть, шигырь-әдәбият кирәк. Хәтта берсендә шулай Троицкидәнме каяндыр адресымны табып, миңа зур шагыйрь итеп эндәшеп, шигырьләремне яратуларын язып, мәктәптә "әйтү" өчен шигырьләр сорап кызлардан хат килеп төште. Миңа? Эле бу чагыда авылда ялан аяк ат булып яр башында чапкан малайга! Күрәсең, ул дәвердә шигырь-әдәбият татар тормышында шулхәтле киң халык массаларының зарурый таләбенә әйләнгән ки, мондый атмосферада минем шикелле малайларның да яшьтән үк каләмгә сарылуларына һич тә гаҗәпләнергә ярамый»*, – нәтиҗә ясый Н. Исәнбәт [Исәнбәт, Мин ничек..., б. 17].

«Хәсәния» мәдрәсәсендә Н. Исәнбәт тарихчы, җәдидчелек хәрәкәтенең алдынгыларыннан булган, Оренбург Мөселманнар Диния нәзарәте казые, дөньяны тануның яңа ысулларын яклап чыккан Хәсән Гата Габәши китапларын укый [Исәнбәт, 2000, б. 99]. Ул әтисенең аны Казанга, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга *«Сине хәлфә тарихтан яхшы укый дип мактады, ул мине мәдрәсәдә укытуны, мулла итү өчен түгел, син Мәрҗани кебек галим бул, мөчтәһит бул, ди иде»* [Исәнбәт, 2000, б. 99], – дигән теләкләр белән озатуын искә ала. Н. Исәнбәт шәхесенә «Хәсәния» мәдрәсәсе хәлфәләре шундый офыклар юраган була.

Г. Барудины хөрмәт иткән Сиражетдин мулла улын 1914 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга урнаштыра. Биредә заманында рус-европа гомуми белем бирү мәктәпләрендәге барлык дөньяви фәннәр диярлек укытылган, ә кайберләре югары уку йортларындагылар белән тәңгәл килгән. Мәсәлән, XX гасыр башында рус теле, арифметика, матур язу, рәсем (сызым), хисап, география, физика (табигать белеме), Россия тарихы, гомуми тарих, төрки халыклар тарихы, фән һәм сыйныфлар тарихы, фәраиз (мирас бүлү турындагы фән), этика, гигиена, юриспруденция, метрика, риторика, психология, мантыйк (логика), фәлсәфә, укыту методикасы, педагогика, гарәп теле, фарсы теле, гарәп әдәбияты укытылган. Табигый ки, иншалар, изложениеләр язылган, төрле текстлар да ятланган. Татар теленә килгәндә, ул гомумтөрки тел буларак укытылган, ә туган телдә уку исә «караәте төрки» (төркичә уку) дип аталган.

С. Кудаш Н. Исәнбәт яшьлек еллары турында болай яза: «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укыганда, *«Безнең 15 яшьлек шагыйребезгә*

*кинәт күк капусы ачылып китә. Ул беренче тапкыр шигърияттән имтихан тота. 1915–1916 елларда „Аң“ һәм „Сөембикә“ журналларында аның бер-бер артлы өч поэмасы басылып чыкты. Шуның өстенә ул 1913–1917 елларда Казанда балалар өчен чыгарылган „Ак юл“ һәм „Балалар дөньясы“ журналларында бастырган матур шигырьләре белән балаларның сөеп укыган бер шагыйренә әйләнә»* [Кудаш].

Истәлекләрендә Н. Исәнбәт мәдрәсәдә татар телен һәм татар әдәбиятын Г. Ибраһимов дәреслекләре һәм уку әсбаплары буенча укыганлыгын телгә ала: *«Без, шәкертләр, Г. Ибраһимовның шул дәреслекләре буенча укыдык. Шулай ук аның „Табигать балалары“ һәм „Алмачуар“ кебек хикәяләрен дә бик яратып укый идек»* [Исәнбәт, Остазым иде..., б. 19.].

Н. Исәнбәтнең баштагы шигырьләрендә ул заманның танылган шагыйрьләренең, бигрәк тә Г. Тукайның тәэсире нык сизелә. Уфада «Хәсәния» мәдрәсәсендә 1912 елда язган «Шул кайната минем каннарымны» исемле шигыре аеруча игътибарга лаек. Н. Исәнбәт әсәрләрендә тормыштагы хаксызлыкка-гаделсезлеккә каршы чыга [Исәнбәт, 1989, б. 21]. Аның шигырьләрендә тәнкыйть мотивлары көчле булганын күрә алабыз. Язучының герое милләткә хезмәт итү идеясе белән яна («Милләтем» (1913)) [Исәнбәт, 1989, б. 24]. Шагыйрь үзенең җырлары тәрәккыят эшенә хезмәт итсен дип хыяллана. Исәнбәтнең тарихи фикерләве Идел һәм Болгар, ата-бабаларның героик үткәне турында уйлануларында чагыла («Моңланам мин...» (1913), «Иделдә» (1914), «Болгар ярларында көймәдә» (1915), «Болгар хәрабәләре» (1915)) [Исәнбәт, 1989, б. 27–28, 36–37]. Соңрак үзенең тарихи драмаларында һәм трагедияләрендә язучы милли каһарманнарның тулы бер галереясен тудыра, алар башкаларга да әхлакый үрнәк була ала дип саный.

Шигырьләрендә яшь шагыйрь табигать («Кышкы төндә» (1913), «Төнге буранда» (1915) «Куркыныч төн» (1915), «Яшен астында» (1915), «Җәйге таң» (1916), «Җәйге кич» (1916), «Көзге курайлар» (1916), «Җәйге төн» (1916), «Күләгә» (1916)) [Исәнбәт, 1989, Б. 23, 35, 39, 51, 55], авыл күренешләрен («Авылга карап» (1913), «Авыл хәлләре» (1913), «Күрмиләр» (1915)) [Исәнбәт, 1989, б. 23, 25, 32], татар хатын-кызлары язмышы хакындагы уйлануларын («Татар кызына» (1915), «Татар хатыннарына» (1915), «Җырла, татар кызы!» (1916)) [Исәнбәт, 1989, б. 35, 38, 40], мәхәббәт кичерешләрен («Үләр идем» (1913), «Бәхет йолдызы» (1914), «Таң җилендә»(1916), «Пароходта» (1916), «Күзләре» (1916), «Көл эле» (1916), «Ылаклы мәгаләләре» (1916), «Фатыйма» (1916)) бирә [Исәнбәт, 1989, б. 26–27, 40–44] , фәлсәфи карашлары белән («Кызык адәм», (1912), «Сугыш» (1914), «Яшь күңел» (1915), «Моңлы көй» (1915), «Пәйгамбәр» (1915), «Богауда» (1915), «Дүрт ягың кыйбла!» «Тагы...» (1916), «Кеше тавышы» (1916), «Ут диңгезендә» (1916), «Сихерче» (1916), «Тормыш упкынында» (1916), «Сөргән» (1916), «Артык кеше» (1916), «Юлда» (1916), «Туган ил» (1916)) уртаклаша [Исәнбәт, 1989, б. 20, 30–31, 33–34, 45–46, 48–49, 54–57]. Н. Исәнбәт башлангыч чорда күбрәк романтик рухлы әсәрләр яза. Язучы үз тавышын, үз юлын табарга омтыла. Аның әсәрләре матбугатта еш күренә башлый («Ак юл», «Сөембикә», «Аң», «Ялт-йолт» журналлары, «Сүз» газетасы).

Шәкертлек чорында Н. Исәнбәт – киң колачлы поэмалар авторы да («Бозылган вәгъдә» (1913), «Качкын» (1915), «Табигать кочагында» (1916), «Укытучы кыз» (1916), «Сукбай» (1916)). Н. Ханзафаров фикеренчә, бу әсәрләрдә «саф мәхәббәт, табигый матурлык, җан җылысы эзләү темалары романтик, экспрессив дулкыннарда ачыла» [Исәнбәт, 1989, б. 6].

Н. Исәнбәт белән Ф. Бурнаш, «Мөхәммәдия»дә укыганда, берничә кулъязма әдәби-сатирик журнал чыгаралар.

*«Ак юл» журналында басылган «Кем?» шигырендә мин өч мөкатдәс нәрсә – Алла, ана, ата турында язганмын. Димәк, 1915 елда әле мин Аллага ышанганмын,* – дип уйлана Н. Исәнбәт үзенең хатирәләрендә. – *Ышануым, үземчә «фәлсәфи» мәгънәдәрәк булса да, булган һәм бу ышану 1917 елга кадәр дәвам иткән. Әмма шул ук вакытта, 1916 елда, минем инде тәңрегә карата үземне бәйсез тотуым шигырьләремдә чагыла. Мәсәлән, 1916 елда «Аң» журналына бирелеп тә басылмыйча кире кайтарылган «Мин ачуландым» шигыре шундый. Анда мондый юллар бар: Кит әле, ялган кеше, / Мин сөймимен беркемне дә, / Сөймимен җир-күк, кояшны, / Сөймимен тәңремне дә* [Ханзафаров, б. 12].

Н. Исәнбәт Казаннан туган ягына шигырьләре өчен даими гонорарлар килеп торган шагыйрь булып кайта. Әтисе бу хәлгә бик нык гаҗәпләнә: *«Минем бар омтылышым –*

*шагыйрь булу, әти ул эшемә каршы түгел, әмма җитди эш итеп карамый иде. Әмма 16 нчы елда Казанда „Аң“ журналында басылган поэмаларыма гонорар килеп төшкәч, бик гаҗәпләнде, ничек, шигырь язганга акча түлиләрме?»* [Исәнбәт, 2000, б. 99].

Казан, Уфа, Оренбург шәһәрләре мәдрәсәләрендәге шәкертләр арасында сәнгатькә омтылу аеруча көчле була. Алар үз көчләре белән әдәби кичәләр уздыралар, спектакльләр куялар. 1913 елда Н. Исәнбәт, Г. Камал йогынтысында, «Урнаш» исемле беренче пьесасын яза. 1914 елда ул «Әмирхан хәзрәт» пьесасын иҗат итә. Шәкертлек чорында ук Нәкый үзен драматург буларак таныта.

Язучының истәлекләре безгә шулай ук шәкертләрнең мәдрәсәдә белем алу чорында нинди вакытлы матбугат укыганын ачыкларга мөмкинлек бирә. Сираҗетдин мулла Малаязга «Дин вә әдәп» (Казан, мөх. Галимҗан Баруди), «Ак юл» (Казан, мөх. Фәхрелислам Агиев), «Мәгълүмате җәдид» (Уфа, мөх. Локманхәким Ханзафаров) журналларын, «Йолдыз» (Казан, мөх. А.-Х. Максуди), «Сибирия» (Томск, мөх. В. Нәүрузов), «Тормыш» (Уфа, мөх. В. Нәүрузов, З. Кадыйри, Г.Хәбиров) газеталарын яздыра [Исәнбәт, 2000, б. 99].

Моннан тыш, Нәкый шәкертлек чорында Нисебаш авылындагы туганнарының китапханәсендәге китапларны да укый: *«Шәмсенур җиңги мине үзләренең өй түбәсенә мендереп җибәрә башлады. Менә кайда икән ул минем өчен татарның ачылмаган Америкасы! Дөнья! Анда әрҗәләргә 5 нче елның революцион матбугаты – „Таң“нар, „Фикер“ләр, „Урал“, „Азат халык“лар, „Әлгасрелҗәдит“, „Уклар“, „Әлъислах“лар, хәтта кызыл кәгазьдә басылып чыкканнары да, җилем басмада басылган революцион „Сада“лар да ята иде. Болар берсе дә хөкүмәт газеталары түгел, байтагы цензурсыз ук чыккан. Боларда татар үз эчке иҗтимагый хәлен, беркемнән дә сорамыйча, үзе өчен үзе хәл итә, үз кайгысын үзе кайгыртып, уртага салып сөйләшә, хөкүмәтне тәнкыйть итә, кыю матбугат иде, ягъни колонизатор патша хөкүмәтен таныганда, гасырлар буена буылып килгән татар җәмәгатьчелек фикеренең революция аркасында берьюлы ерылып, шаулап агуы, ирекле татар матбугатының беренче еллары, гаҗәп кызык матбугат.*

*Мин малай шагыйрь, күрәсез, нәкъ шул 1905 нче ел матбугатын 10 нчы елларда укып ятам...* » [Исәнбәт. Мин ничек..., б. 14.].

Н. Исәнбәтнең агарту эшчәнлеге аның дөньяга карашларының эволюциясе өчен закончалыклы һәм зарури баскыч була: ул дини карашлардан татар мәгърифәтчелегенең иң яхшы традицияләренә (Х. Фәезханов, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал) нигезләнгән агарту-мәгариф эшчәнлегенә кадәр юл үтә. Язучы яшьлегендә Г. Камал, Ф. Әмирхан, М. Фәйзи иҗатлары белән таныш булуы турында яза: *«Г. Камал, Ф. Әмирхан, М. Фәйзи иҗатлары белән дә таныш идем»* [Ханзафаров, б. 12].

Җәдидчелеккә багышланган хезмәтендә Н. Исәнбәт 1905 елгы инкыйлабтан соң татар мәдрәсәләрендәге тормышның кискен үзгәреп китүе турында яза. Шәкертләр үзләрен мәдәни һәм белем бирү өлкәсендә генә түгел, сәяси аренада да күрсәтәләр. Бергәләп мәдрәсәне ташлап китү шәкертләр протестының төп формасына әверелә. Н. Исәнбәт бу күренеш хакыйкатькә якын итеп сурәтләнгән әсәрләргә мөрәҗәгать итәргә тәкъдим итә (Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романы [Ибрагимов], С. Рәмиевнең «Низамлы мәдрәсе» комедиясе [Рәмиев, б. 73–92]. Шәкертләр ул чорда җилем матбугаларда садә һәм марсельезалар басып тараталар, шуларны җырлыйлар иде. «Ислах»чылар шундый революцион алымнар белән мәдрәсә-стачкалары һәм забастовкалар оештыра башлыйлар.

Шәкертләр лаеклы һәм кызыклы тормыш турында хыялланалар, аларның тормышта үз урыннарын табасылары, мул тормышта яшиселәре килә. Революция чоры шәкертләре субкультурасында дини бәхәсләрне әдәби-сәяси түгәрәкләр алыштыра. Аларда төрле темаларга әңгәмәләр, дискуссияләр, әдәби-музыкаль кичәләр уздырыла.

1976, 1989 елларда язучы 3 томлы «Сайланма әсәрләр»ен һәм 4 томлы «Әсәрләр»не басмага әзерләгәндә, аларга «Хәсәния» һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәләре шәкертләре тормышына багышланган өч шигырь кертә. Аларда Н. Исәнбәт үзен ирексөючән шәкерт итеп мәңгеләштерә.

«Иттифак җиңә» шигыре (1909) шәкертләрнең торак шартлары аркасында мөгаллим Зөфәр Касыймов белән бәрелешкә керүләренә багышлана [Исәнбәт, 1989. б. 14–15 б.] Күрәсең, алар, 1905–1907 еллар инкыйлабы

елларындагы Уфа һәм Казан мәдрәсәләрендәге забастовкалар мисалында, үз хокуклары өчен көрәшә башлыйлар. «Мәдрәсә истәлеге» шигырендә Н. Исәнбәт, кулъязма юмористик журнал чыгарганы өчен, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллимнәре белән каршылыкка керүе хакында яза. Үз язу өстәленең кич белән тентеләсен белеп, яшь шагыйрь аның эченә мөгаллимнәренә үзенең җинаятьче булмавын белдереп язу тыгып калдыра («бер хаин дип уйлыйлар»): «Сөйми һич иркен җаным зиндан, богау һәм тикшерү; / Ак күңел мин, ят миңа бу арт күзәтеп эш күрү» [Исәнбәт, 1960, б. 71, 450].

Н. Исәнбәт һәрвакыт мәдрәсәдә укыган еллары турында бик яратып искә ала. М. Усманов студентлык елларында аксакалга кунакка килүе, аның шәкертләр, мәдрәсә тормышы хакында сөйләгәннәрен тыңлавы турында искә ала. Шәкертләр бергә ашыйлар, бергә эшлиләр, дежур торалар. Дежур шәкерт, мәсәлән, идән себерә, мичкә яга, намаз укымаучыларны тотып, хәлфә янына алып килә. Н. Исәнбәт университет студентларына шәкертләрнең күңел ачулары турында да сөйли, «мендәрләр белән сугышуларын» бик кызыклы итеп сурәтли [Госманов, б. 124].

Истәлекләрдән күренгәнчә, мәдрәсәдә «дедовщина» очраклары да булган. Мәсәлән, «Җидегәнчелектә гаепләнүләр» мәкаләсендә Н. Исәнбәт «Җәдит өркетү» йоласы турында яза: *«элек иске мәдрәсәгә икенче бер мәдрәсәдән укырга килеп кергән яңа шәкертне бу мәдрәсә җәмәгатенә күнектерү, аның „вакарын җимерү“ өчен „өркетеп“, „эшкәртеп“ алу, көтмәгәндә аны бар көчкә мендәр белән бәреп әчелеккә егалар, торып басканчы үзенә каяндыр, каталар белән җибәрәләр, дуңгыз булып ян-яктан мыркылдап өстенә киләләр. Шәкерт үзенең чаршау бүлмәсе эченә качып та котыла алмый: атлар булып пошкырып килеп, чаршау артыннан тибәләр. Каз булып какылдап кыскыч борыны белән җилкәсен чукыйлар, әйләнеп тотыйм дигәнче чаршау артыннан әллә каян сузылып, ясап куйган чәенә учлап тоз салалар. Кыскасы, берничә көн буе шундый вәхшилекләр белән чыныктырганнан соң шәкерт бу мәдрәсәнең менә дигән үз кешесе булып, җитә һәм үзе дә яңа килүче шәкертләргә шул ук эшләрне эшли башлый».* [Җидегәнчелектә гаепләнүләр, б. 3].

Н. Исәнбәт, шәкертләргә багышлап, «Бер шәкерт» исемле шигырь яза. Әсәрдә шәкертләрнең хыяллары белән уртаклаша:

Төн... тирә якты тынычлык.
Ул үзен уйлый хәзер:
Ул – художник, ул – музыкант,
Ул – мөхәррир, ул – шагыйрь!

Ул – тагын, тиздән белерсез,
Дөньяда бер бай кеше.
Акча күплектән, «халыкка
Файда» – һәр кылган эше.

Ул татарга әллә ниткән
Зур клублар салдыра,
Бакчалар, фонтан, сарайлар...
Дөньяны таң калдыра. [Исәнбәт, 1989, б. 47–48].

Җәдиди мәдрәсәләр XX гасыр башында зыялылар тәрбияләү урынына әверелә. Н. Исәнбәт үзенең җәдидчелек турындагы хезмәтендә С. Кудаш Уфадагы «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаучылар буенча ясаган статистиканы күрсәтә: 1906–1919 елда белем алган 1500 шәкертнең бары 27 се генә мулла була. С. Кудашның 100 танышы арасында 20 се – профессиональ язучы, 28 е – журналист, газета редакторлары, 58 е – галим, 4 се – дипломат, 6 сы – агроном, 3 се – инженер, 3 се юрист була, 6 сы ТАССР, БАССР, Казахстанның мәгърифәтчелек министерстволарын җитәкли, 2 се – артистлык, 1 се – композиторлык, калганнары укытучылык юлын сайлый [Җәдидчелек мәсьәләсе, б. 39].

1965 елда яшь язучы Р. Батулла белән сөйләшкәндә, аксакал: *«Мәдрәсәләрдә шигырь, әдәбият яхшы укытыла иде. Хәзер университет бетергәннәр дә ибтидаи мәктәп шәкерте белгән чаклы борынгы әдәбиятны белми. Гарәпчә, фарсы, төрекчә язуны әйтмим дә инде»*, – ди. [Батулла, 2007, б. 233].

1968 елда үзенең тормыш һәм иҗат юлын *«Мин революциягә чаклы өлгергән шагыйрь идем инде. Мин галим. Мин энциклопедияче. Драматургия белән мин гаиләмне туйдыру өчен генә шөгыльләнә башладым. Әнә шул шөгыль мине суырып алды да драматург итте дә куйды. Галимме мин? Әлбәттә, галим. Ләкин мин диссертациясез, званиясез, кафедрасыз галим! Монысы инде совет властеның намусында»*, – дип бәяли «халык академигы». [Батулла, 1997, б. 195].

## Нәтиҗәләр

Н. Исәнбәт иҗатында шәкертлек чоры турында бик күп кызыклы мәгълүмат тупланган. Бу материал нигезендә, без, язучы биографиясе белән якыннан танышып, татарларның XX гасыр башындагы көндәлек

тормышы турында да фикер йөртә алабыз. Н. Исәнбәт романтик әсәрләрендә шәкертләр тормышын ироник, сатирик планда ачса, хатирәләрендә, автобиографик әсәрләрендә шәкертләр көнкүрешен, аларның иҗтимагый тормышын, әхлакый һәм эстетик фикерләрен, үз-үзләрен тотышларының социаль һәм индивидуаль чагылышларын, үзара мөнәсәбәтләрен тасвирлый.

**Әдәбият**

Әдип һәм галим. Казан : Татар. кит.нәшр., 1969. 124 б.

*Батулла Р.* Тузга язмаган хәлләр. Казан : Татар. кит. нәшр., 2007. 447 б.

*Батулла Р.* Урыннары җәннәттә булсын! Казан : Татар. кит. нәшр., 2007. 902 б.

Ватан сездән эш көтә!: [Н. Исәнбәтнең 1979 елның 28 ноябрендә «Яшь ленинчы» редакциясендә сөйләгәннәреннән Шәвәли язып алганнарының бер өлеше] // Яшь ленинчы. 1980. 26 гыйнвар.

*Гайнанов Р.* Халыкка хезмәткә // Азат хатын. 1959. №12. Б. 10.

*Галиуллин Т.* Егерменче еллар татар шигърияте // Шигърият баскычлары. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 72–73.

*Госманов М.* Аксакаллар мәҗлесеннән: [Нәкый Исәнбәт тур. истәлекләр] // Казан утлары. 2010. № 11. Б. 121–135.

*Еники Ә.* Нәкый Исәнбәт // Хәтердәге төеннәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 3–7 б.

*Исәнбәт Н.* Сайланма әсәрләр : 3 томда, 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. 915 б.

*Исәнбәт Н.* Шәйхзадә Бабич: Истәлек // Казан утлары. 1967. № 6. 127–134 б.

*Исәнбәт Н.* Әсәрләр : 4 томда, 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 310 б.

*Исәнбәт Н.* Остазым иде... // Казан утлары. 1987. Б. 19.

*Исәнбәт Н.* Бәби чак: [Истәлекләрдән] // Мирас. 1999. № 12. Б. 95–104.

*Исәнбәт Н.* Бәби чак: [Истәлекләрдән] // Мирас. 2000. № 1. Б. 91–101.

*Исәнбәт Н.* Мин ничек шагыйрь булдым // Н. Исәнбәтнең шәхси архивы, кульъязма. Машинкада басылган. [Датасыз]. Б. 13–27.

*Исәнбәт Н.* Җәдидчелек турында // Н. Исәнбәтнең шәхси архивы, кульъязма. Машинкада басылган. [Датасыз]. 30 б.

*Исәнбәт Н.* Җидегәнчелектә гаепләнүләр. // Н. Исәнбәтнең шәхси архивы, кульъязма. Машинкада басылган. [Датасыз]. 3 б.

*Кандалый Г.* Шигырьләр һәм поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 558 б.

*Кудаш С.* Хәтердә калган минутлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 284 б.

*Кудаш С.* Минем баһадир замандашым // Социалистик Татарстан. 1980. 15 гыйнвар.

*Рәмиев С.* Низамлы мәдрәсә // Рәмиев С. Таң вакыты. Казан : Татар. кит. нәшр., 1980. Б. 73-92.

*Тукай Г.* Әсәрләр: 5 т. Казан : Татар. кит.нәшр., 1985. 406 б.

*Ханзафаров Н.* Нәкый Исәнбәт драматургиясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 192 б.

*Шамуков Г.* Нәкый Исәнбәт. Казан : Татар. кит.нәшр., 1959. 76 с.

*Фәхреддин Р.* Асар. Т. 3-4. Казан, 2010. 648 б.

*Арсланов Г.* Фольклорный театр Наки Исанбета: «Идегей» и «Ходжа Насретдин» // Гасырлар авазы. 2012. №1/2. С. 251-254.

*Бергер П., Лукман Т.* Социальное конструирование реальности. Трактат по социологии знания [Текст] / П. Бергер, Т. Луман. М.: Медиум, 1995. 323 с.

*Бикбаев Р. Т.* Творческий путь Шайхзады Бабича в памяти родного народа (к 120-летию со дня его рождения) // Проблемы востоковедения. 2014. №4 (66). С.38.

*Габдрафикова Л. Р.* Повседневная жизнь городских татар в условиях буржуазных преобразований второй половины XIX – начала XX века. Казань: Институт истории АН РТ, 2013. 384 с.

*Габдрафикова Л. Р.* Татарское буржуазное общество: стиль жизни в эпоху перемен (вторая половина XIX – начало XX века). Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. 367 с.

*Габдрафикова Л. Р.* Культура чтения в Мензелинске во второй половине XIX – начале XX вв. // Научный Татарстан. 2018. № 1. С. 54–62.

*Габдрафикова Л. Р.* Забытая тетрадь татарского шакирда эпохи революции: 1909–1918 (воспоминания Шарифа Замилова) // Историческая этнология. 2017. № 2. С.346–358.

*Габдрафикова Л. Р.* Татарская литература рубежа XIX–XX вв. как исторический источник // Татарика. 2016. № 7. С.109–125.

*Ибрагимов Г.* Наши дни. Москва : Советский писатель, 1980. 416 с.

*Исанбет Ю.* Лишь труд дает пустыням воды // Казань. 2011. № 2 С. 102–109.

*Лотман Ю. М.* Беседы о русской культуре : быт и традиции русского дворянства (XVIII – начало XIX века). СПб.: Искусство, 1994. 412 с.

«Об ошибках в учебнике литературы для 8 класса татарских средних школ» // История татар с древнейших времен в 7 т. – т. VII – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2013. С. 861–862.

*Сенюткина О. Н.* Архивные материалы и история повседневности (о татарской деревне Шубино XIX столетия) // Фаизхановские чтения. №7 (2010) // URL: http://www.idmedina.ru/books/ materials/?3254 (дата обращения 15.10. 2019).

*Струкова. Т. Г.* Проблема обыденности в дискурсе о литературе // Вестн. ВГУ. Сер. Философия. 2017. № 1. С. 72–83.

*Утябай-Карими Р.* «Хасания» // Башкирская энциклопедия. Т. 7. Уфа: Башкирская энциклопедия, 2009. С. 128.

*Фрейд З.* Психопатология обыденной жизни. Толкование сновидений. Пять лекций о психоанализе. М.: Эксмо, 2016. 618 с.

*Фукс К. Ф.* Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. Казань: Изд-во «Познание» Института экономики, управления и права, 2013. 108 с.

*Хабутдинов А. Ю., Хабутдинова М. М.* Образ Наки Исанбета в татарской прозе // Филология и культура. Philology and Culture. 2019. №4 (58). С. 191-201.

*Хаплехамитов Р.* Первые годы постсталинского периода в Татарстане: взаимоотношения власти и творческой интеллигенции // Известия Самарского научного центра Российской академии наук. Т. 10, №1, 2008. С. 136-140.

*Эко У.* Отсутствующая структура: Введ. в семиологию / Умберто Эко; [Пер. А. Г. Погоняйло, В. Г. Резник]. СПб. : Петрополис, 1998. 430 с.

---

# ПОВСЕДНЕВНАЯ ЖИЗНЬ ШАКИРДОВ ТАТАРСКИХ МЕДРЕСЕ В НАЧАЛЕ XX ВЕКА В ВОСПОМИНАНИЯХ НАКИ ИСАНБЕТА

**Милеуша Мухаметзяновна Хабутдинова,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
mileuscha@mail.ru.

Наки Сиразиевич Исанбет (1899–1992) – татарский писатель, поэт, драматург, прозаик, фольклорист, ученый-энциклопедист. Пламенный патриот родной земли видел свою миссию в служении татарской литературе, татарскому языку, а через них – татарскому народу. В его наследии содержатся интересные сведения об истории образованности татар. Материалом для исследования повседневной жизни шакирдов татарского медресе послужили воспоминания, стихотворения, автобиографическая повесть писателя «Бәби чак» («Детство») и другие архивные документы. Эти источники позволяют сформировать объективную картину формирования татарской интеллигенции в начале XX в. Если в романтических произведениях Н. Исанбета жизнь шакирдов и медресе раскрывается преимущественно с долей иронии и в сатирическом плане, то в его реалистических произведениях и воспоминаниях доминирует просветительский пафос. Н. Исанбет гордится системой образования татар Нового времени и считает медресе настоящей кузницей татарской национальной интеллигенции.

**Ключевые слова:** татарская литература, Н. Исанбет, татарское медресес, мир шакирдов, повседневность.